**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлегенең Кече Әтнә торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

"19" ноябрь 2023 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Олы Әтнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы, «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Олы Әтнә авыл җирлеге Советының 25.10.2019 ел №126 карары нигезендә, 2023 елның 19 ноябрендә «Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Олы Әтнә авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 18 яше тулган һәм тавыш бирү хокукына ия булган һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1 төркем инвалидлардан тыш, мобилизацияләнгән гражданнарны һәм аларнын гаилә әгъзаларын, РФ Оборона министрлыгы белән контракт төзегән хәрби хезмәткәрләрдән һәм РФ Оборона министрлыгы белән контракт төзегән хәрби хезмәткәрләрнең гайлә әгъзаларыннан тыш һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү буенча түбәндәге эшләрне башкару:

1) Кече Әтнә авылының Совет, К. Маркс һәм Тукай урамнарын төзекләндерү һәм чистарту (үлән кисү, агачлар,куаклар, үсентеләр кисү, каты көнкүреш калдыклары полигонына кадәр алып китү);
2) Кече Әтнә авылы торак пунктының урам юлларын ремонтлау һәм каплау (вак таш сатып алу, капламаларны ремонтлау һәм урнаштыру буенча хезмәт күрсәтүләргә түләү);
3) Спорт мәйданчыгы төзү һәм балалар мәйданчыгын ремонтлау.
4) Кече Әтнә авылы зиратын карап тоту һәм төзекләндерү;

«РИЗА» «КАРШЫ»

«2022 елда гражданнар җыены белән билгеләнгән спорт мәйданчыгы төзү өчен 27000 сум күләмендә гражданнарның кулланылмаган үзара салымы акчаларын түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә ризамы:

1) Спорт мәйданчыгы төзү һәм балалар мәйданчыгын ремонтлау

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

**Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:**

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 178 (йөз җитмеш сигез) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 120 (йөз егерме) , 67,4%.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 97 (йөз алты) кеше тавыш бирде, 80,8%;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 23 (егерме өч) кеше тавыш бирде,19,2%.

**Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Кече Әтнә авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – **дөрес дип таныrга**.

"Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Олы Әтнә авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 18 яше тулган һәм тавыш бирү хокукына ия булган һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1 төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнарны һәм аларнын гаилә әгъзаларын, РФ Оборона министрлыгы белән контракт тозегән хәрби хезмәткәрләрдән һәм РФ Оборона министрлыгы белән контракт тозегән хәрби хезмәткәрләрнең гайлә әгъзаларыннан тыш һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү буенча түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме":

1) Кече Әтнә авылының Совет, К. Маркс һәм Тукай урамнарын төзекләндерү һәм чистарту (үлән кисү, агачлар ,куаклар, үсентеләр кисү, каты көнкүреш калдыклары полигонына кадәр алып китү);

2) Кече Әтнә авылы торак пунктының урам юлларын ремонтлау һәм каплау (вак таш сатып алу, капламаларны ремонтлау һәм урнаштыру буенча хезмәт күрсәтүләргә түләү);

3) Спорт мәйданчыгы төзү һәм балалар мәйданчыгын ремонтлау;

4) Кече Әтнә авылы зиратын карап тоту һәм төзекләндерү;

"Сез 2022 елда гражданнар җыены белән билгеләнгән спорт мәйданчыгы төзү өчен 27000 сум күләмендә гражданнарның кулланылмаган үзара салымы акчаларын түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә ризамы":

1) Спорт мәйданчыгы төзү һәм балалар мәйданчыгын ремонтлау -

**мәсьәләсен кабул итәргә**.

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнәавыл җирлеге Кече Әтнә авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Кече Әтнә авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма
комитет җитәкчесе: Порфирьев С.Н.